ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 июнь, 2017 ел № 17/8

Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына
үзгәрешләр кертү турында

Магистраль нефтьүткәргечтән минималь мөмкин булган ераклык зонасына керүче җир кишәрлекләрен чыгару һәм Яр Чаллы шәһәре Генераль планын килештерү һәм раслау тәртибен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 маддәсенә туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 2 маендагы 10-53/5388 санлы Яр Чаллы шәһәре Генераль планына үзгәрешләр кертү проектына Бәяләмәсенә нигезләнеп, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсе, шәһәр Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2006 елның 27 июнендәге 14/4 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына магистраль нефтьүткәргечтән минималь мөмкин булган ераклык зонасына керүче җир кишәрлекләрен чыгару өлешендә 1, 2, 3 кушымталардагыча үзгәрешләр кертергә.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2014 елның 9 декабрендәге «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» 35/11 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2014 елның 24 декабрендәге 96 санында басылган);

2) Шәһәр Советының 2016 елның 24 февралендәге «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» 6/11 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2016 елның 4 мартындагы 16 санында басылган);

3) Шәһәр Советының 2016 елның 8 июлендәге «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планы сызымына үзгәрешләр кертү турында» 9/4 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2016 елның 15 июлендәге 51 санында һәм 2016 елның 20 июлендәге 52 санында басылган);

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев